ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423750, Уразай авылы,
Центральная урамы, 4 нче йорт.
тел.3-44-62
e-mail : Uraz.Akt@tatar.ru

УРАЗАЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423750, дер.Уразаево,
ул.Центральная,
дом 4., тел. 3-44-62.
e-mail : Uraz.Akt@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«04» октябрь 2024 ел № 7

**Уразай авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 26 октябрендәге 11 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуның план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 01 декабрендәге 2151 номерлы карары нигезендә, Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Уразай авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 26 октябрендәге 11 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуның план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Федераль законның 82 статьясы нигезендә сатып алулар гамәлгә ашырылган очракта план-графикка үзгәрешләр кертү сатып алуларда катнашучыларга котировкалар бирү турында гарызнамә җибәрелгән көннән дә соңга калмыйча, ә Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешенең 9 пункты нигезендә бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) сатып алу башкарылган очракта - контракт төзелгән көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»

1.2. 11 пунктны РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 30 сентябрендәге «Сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау тәртибен билгеләү, мондый план-графикларга үзгәрешләр кертү, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алуларның план-графикларын урнаштыру, мондый план-графикларга мәгълүмат кертү үзенчәлекләре һәм сатып алу план-графиклары формасына таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 1279 номерлы карары нигезендә үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«13. План-график Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау, мондый планнарга үзгәрешләр кертү,

сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алуларның план-графикларын урнаштыру, мәгълүматны сатып алуларның план-графикларына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2019 елның 30 сентябрендәге 1279 номерлы карары белән расланган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүнең план-графигы формасына карата таләпләр нигезендә формалаштырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында (http//pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче

Башкарма комитет җитәкчесе Шаймарданова Г.С.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОГРН 1061688003855
УРАЗАЕВСКИЙ сельский исполнительный комитет
ИНН 1604006871